Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советы

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

23 ноябрь 2018 ел №114

**Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советынын 2014 елның 20 ноябрендәге 135 санлы «Физик затлар милкенә салым турында» гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлеше 2 пункты, «Россия Федерациясе Салым кодексының 52 статьясына беренче һәм икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 3 августындагы 334 - ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Салым кодексының 2000 елның 5 августындагы 117-ФЗ номерлы Федераль законның 56, 399 статьяләренә нигезләнеп, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставына, Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советы карар итте:

1.Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советының 20.11.2014 ел, 135 санлы «Физик затлар милкенә салым турында» гы карарына (Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр., 29.05.2015 ел,№158, 30.10.2015 ел, № 12, 10.07.2018 ел, № 96) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1) 2.2.1.подпунктына «фатирлар» сүзеннән соң «фатир өлешләре» сүзләрен өстәргә.

2) 2.3.1. подпунктына«торак йортлар» сүзләреннән соң «торак йортларның өлешләре» сүзләрен өстәргә.

3) 2 нче пунктка түбәндәге эчтәлектәге 2.7 нче подпункт өстәргә:
«2.7. Ел башына унсигез яше тулмаган өч һәм аннан да күбрәк балалары булган күп балалы гаиләнең, шул исәптән үги балалары, опека һәм попечительлеккә алынган балалары булганкүп балалы гаиләнең,ата-ананың икесенең берсенә салым салынучы бер объектына (сайлап алып)физик затлар милкенә салымның түбәнәйтелгән ставкасы рәвешендә салым ташламасын билгеләргә:

| Объект төре | Гамәлдәге ставка | Ташламалы ставка |
|---|---|---|
| Шәхси торак йорт яки торак йортның бер өлеше | 0,3 | 0,15 |
| Күп фатирлы йортта торак бина (фатир, фатирның бер өлеше, бүлмә) | 0,2 | 0,1 |

Салым ташламасына хокукны раслаучы документлар салым түләүчеләр - физик затлар тарафыннан салым салу объекты булган мөлкәтурнашкан урындагы салым органнарына, үткән салым чорыннан соң килүче елның 1 февраленнәндә соңга калмыйча, тапшырыла.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» бастырып чыгарырга (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә, шулай УК мәгълүмат и стендларда урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә ләкин халыкка игълан ителгән көннән соң берайдан да иртәрәк түгел.

4.Әлеге карарныңүтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советы Рәисе
«Җәлил шәһәр тибындагы поселогы»
муниципаль берәмлеге башлыгы Р.Ә. Кәримов